ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

10 октябрь, 2014 ел Казан ш. № 5-11/тэ

***Кулланучыларга җылылык белән тәэмин итүче оешмалар тарафыннан җибәрелә торган җылылык энергиясенә тарифларны билгеләү турында***

“Җылылык белән тәэмин итү турында” 27 июль, 2010 ел, №190-ФЗ Федераль закон, “Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә бәя хасил итү турында” 22 октябрь, 2012 ел, №1075 Россия Федерациясе Хөкүмәте карары, “Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә җайга салынулы бәяләрне (тарифлар) исәпләү буенча методик күрсәтмәләрне раслау турында” 13 июнь, 2013 ел, №760-э Федераль тарифлар хезмәте боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 15.06.2010 ел, №468 карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмәгә таянып, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга кушымта нигезендә, кулланучыларга җылылык белән тәэмин итүче оешмалар тарафыннан җибәрелә торган җылылык энергиясенә тарифларны билгеләргә.
2. Бу карарның 1 пунктында билгеләнгән тарифлар карар гамәлгә кергән көннән 2014 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.
3. Бу карар рәсми басылып чыккач ун көннән соң үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Тарифлар буенча
Дәүләт комитеты Рәисе М.Р. Зарипов

Татарстан Республикасы
Тарифлар буенча дәүләт комитетының
10 октябрь, 2014 ел, №5-11/тэ карарына
кушымта

## Кулланучыларга җылылык белән тәэмин итүче оешмалар тарафыннан җибәрелә торган җылылык энергиясенә тарифлар

(НДСтан тыш)

<table>
<tr><th rowspan="2">№ п/п</th><th rowspan="2">Муниципаль берәмлек, җайга салынулы оешма атамасы, тариф төре</th><th rowspan="2">Ел</th><th rowspan="2">Су</th><th colspan="4">Басым белән пар</th><th rowspan="2">Кискен һәм редуцияләнгән пар</th></tr>
<tr><th>1,2–2,5 кг/см$^2$ кадәр</th><th>2,5-7,0 кг/см$^2$ кадәр</th><th>7,0-13,0 кг/см$^2$ кадәр</th><th>13,0 кг/см$^2$ артыграк</th></tr>
<tr><td></td><td colspan="8">Лаеш муниципаль районы</td></tr>
<tr><td>1</td><td colspan="8">“XXI гасыр җитештерү-төзелеш компаниясе” ҖЧҖ</td></tr>
<tr><td>1.1</td><td colspan="8">Тоташтыру схемасы буенча тарифларны дифференцияцияләү булмаган очракта, кулланучылар өчен</td></tr>
<tr><td></td><td>Бер ставкалы, сум/Гкал</td><td>Карар үз көченә кергән көннән 31.12.2014 кадәр</td><td>1384,72</td><td>–</td><td>–</td><td>–</td><td>–</td><td>–</td></tr>
<tr><td>2</td><td colspan="8">“Инженерлык технологияләре” РСК ҖЧҖ * Габишево б.</td></tr>
<tr><td>2.1</td><td colspan="8">Тоташтыру схемасы буенча тарифларны дифференцияцияләү булмаган очракта, кулланучылар өчен</td></tr>
<tr><td></td><td>Бер ставкалы, сум/Гкал</td><td>Карар үз көченә кергән көннән 31.12.2014 кадәр</td><td>1402,58</td><td>–</td><td>–</td><td>–</td><td>–</td><td>–</td></tr>
</table>

<*> салым салуның гадиләштерелгән системасын куллана

Татарстан Республикасытарифларбуенча
Дәүләт комитеты, Тарифларбуенчакарарларны
кабул итү, оештурыһәмҗайга салу бүлеге